БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17 июль 2024 ел № 264

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Яңгул авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлеге территориясенең шәһәр төзелешен планлаштыруны гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясына, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьяларына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына таянып, гавами тыңлаулар һәм килештерү комиссиясе нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2020 елның 19 мартындагы 241 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Яңгул авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең генераль планына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Яңгул авыл җирлеге башкарма комитетына:

- әлеге карарның 1 пункты белән кабул ителгән генераль план нигезендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашырырга;

- Янгул авыл җирлеге торак пунктларының чикләрен күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертергә;

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Яңгул авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең генераль планын раслау турындагы карарны территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасына йөкләүне тәэмин итәргә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi. tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

Балтач муниципаль район Башлыгы урынбасары,
Балтач район Советы рәисе урынбасары Н.Н.Сабирҗанов